| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ул. Нагорная, д.70, с. Тавели, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422160 | Таү өсте урамы, 70 йорт, Тауиле авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы, 422160 |

Тел. (факс): (85563) 2-67-25 e-mail: Tavel.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Постановление

“22” ноябрь, 2018 ел.　　　　　　　　　　　　　　　　№ 17

2018 елның 18 ноябре референдумы
карарын тормышка ашыру максатларында
чаралар планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы, Мамадыш муницпаль районы территориаль сайлау комиссиясенең “Татарстан Республикасы Мамадыш муницпаль районы Тауиле авыл җирлеге территорясендә 2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында” гы 2018 елның 19 ноябренең 904 санлы карары нигезендә, Татарстан Рсепубликасы Мамадыш муницпаль районы Тауиле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. 2018 елның 18 ноябрендәге референдум карарын гамәлгә ашыру максатларында чаралар планын раслау

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе　　　　　　　　　　/В.И.Иванов/

Тауиле авыл җирлеге Башкарма комитетының 22.11.2018 елның 14 санлы карарына 1 нче кушымта

**План мероприятий,**
**в целях реализации решения местного референдума**
**от «18» ноября 2018 года**

| № п/п | Мероприятия | Срок исполнения | Ответственный |
|---|---|---|---|
| 1. | Үзара салым акчасын түләү өчен авыл җирлеге гражданнарының исемлеген әзерләү | 3 декабрьгә кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 2. | Үзара салым акчаларын түләү тәртибе турында гражданнарга хәбәр итү | 10 декабрьгә кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 3. | Үзара салым акчаларын җыю | 28.02.2019 кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4. | Үзара салым акчаларын дөрес исәпләүне, тулысынча һәм үз вакытында түләүне контрольдә тоту | һәрдаим | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 5. | Бирелгән мәгълүматлар буенча үзара салым буенча недоимка торышын анализлау | даими рәвештә | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 6. | Җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларга чыгымнар сметасын раслау | эш тәртибендә, 2019 елның 15 апреленә кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты, Мамадыш муниципаль районы финанс- бюджет палатасы |
| 7. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы | агымдагы финанс елының I кварталы тәмамланганнан соң 15 календарь көн эчендә | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә 1 нче кушымта нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына гариза бирү | | |
| 8. | Акчаның максатчан кулланылышын контрольдә тоту | в течение года ел дәвамында | «ТР Мамадыш муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МКУ |
| 9. | Җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларның үтәлеше турында авыл җирлеге башлыгы отчеты | елга бер тапкыр | Авыл җирлеге башлыгы |
| 10. | Авыл җирлеге башлыгының Җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларның үтәлеше турында отчетын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм (яки) Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерү. | 5 көн эчендә | Авыл җирлеге башлыгы |